| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.12.2018 г. Казань № 228-п

Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарларын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) яңа редакциядә расларга (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 7 августындагы 342-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2015 елның 7 августындагы 342-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 20 июлендәге 281-п номерлы.

3. Районнардагы һәм шәһәрләрдәге дәүләт ветеринария берләшмәләре башлыкларына, Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләренә таянып эш итәргә.

4. Ветеринария эшен оештыру бүлегенә Регламентны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе сайтындагы «Дәүләт хезмәтләре» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

5. Хокук бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасы
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г. Хисаметдинов

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Баш
ветеринария идарәсенең 2018
елның 3 декабрендәге 228-п
номерлы боерыгы белән
расланды

# Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күсәтүнең административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: этләр хуҗалары – этләрне торакта, хезмәт бүлмәсе һәм махсус бүлмәләрдә, шулай ук бу максат өчен махсус бирелгән урыннарда асраучы гражданнар һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Дәүләт хезмәте фәнни, фәнни-тикшеренү, медицина оешмалары өчен фәнни тикшеренү объектлары булган этләрне асрау өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә кагылмый.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан эт хуҗасының яшәү яки тору урыны буенча ведомство карамагындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре (алга таба – ГБУ ГГВО һәм РГВО) аша күрсәтелә.

1.3.1. Ветеринария идарәсе, ГБУ ГГВО һәм РГВО урнашкан урыны, белешмә телефоннары, электрон адреслары әлеге Регламентка 1 нче кушымтада бирелде.

Идарә урнашкан урын: Казан ш., Федосеев ур., 36 йорт.

Идарә, ГБУ ГГВО һәм РГВО эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен, дүшәмбе-җомга 8.00дән 17.00 кадәр, төшке аш 12.00дән 13.00 кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен, Идарә, ГБУ ГГВО һәм РГВО эш сәгатьләрендә.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

1.3.2. Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы Рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керүче рәсми сайты адресы (алга таба – Идарәнең рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре): http://guv.tatar.ru, электрон почта адресы: guv.tatar.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте, шулай ук Идарәнең урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Ветеринария идарәсе, ГБУ ГГВО һәм РГВО биналарында урнашкан дәүләт хезмәте күрсәтү турында текстлы мәгълүматы булган мәгълүмат стендлары

ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Ветеринария идарәсенең рәсми сайтында (http://guv.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Идарәгә, ГБУ ГГВО һәм РГВОга телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Идарәгә, ГБУ ГГВО һәм РГВОга язмача (шул исәптән электрон документ форматында) мөрәҗәгать иткәндә.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында, Татарстан Республикасының ике дәүләт телендәге белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте этләрне тикшерү өчен китергәндә турыдан-туры күрсәтелә.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон белән (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010 ел, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнар җыентыгы 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы № 601номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – № 601 Указ) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2012, №19, 2338 ст.);

«Татарстан Республикасында йорт хайваннарын асрауның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 7 мартындагы № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – № 16 ТРЗ ТР Законы) (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2014, № 3, 206 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, № 26, 12.07.2006 ел, 0647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы

дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – №880 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы», 2010, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карары (алга таба – № 202 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 31, 0965 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Этләрне теркәү тәртибен һәм потенциаль куркыныч этләр токымнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 5 маендагы 298 номерлы карары (алга таба – №298 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 39, 1218 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.6. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

административ регламент – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ гамәлләре вакытын һәм эзлеклелеген, аның структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәтләрен алучылар), дәүләт хакимиятенең һәм җирле үзидарәнең башка органнары, шулай ук оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген билгели торган норматив хокукый акт.

дәүләт хезмәте – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының, җирле үзидарә органының федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә мөрәҗәгать итүчеләрнең гарызнамәләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күп функцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан әлеге мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда

бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсе. Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Административ регламентка 2 нче кушымтада китерелде.

## II. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасында этләрне теркәү | № 16-ТРЗ ТР Законының 8ст., № 298 ТР МК карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Ведомство карамагындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре (алга таба - ГБУ ГГВО һәм РГВО) аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба - Идарә) | № 16-ТРЗ ТР Законының 4ст. 2 өлеше,<br>№ 298 ТР МК карарының 5п,<br>№ 202 ТР МК карарының 3.3.22 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында таныклык бирү (этне теркәү турында таныклыкны алыштыру, таныклык дубликатын бирү, этне теркәү исәбеннән алу) яки таныклык бирүдән баш тарту | № 16-ТРЗ ТР Законының 8ст. 2 өлеше,<br>№ 298 ТР МК карарының 13 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү | Этне теркәү буенча дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне, гаризаны кабул итү һәм теркәүдән соң 2 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә күрсәтелә. | № 16-ТРЗ ТР Законының 8ст.,<br>№ 298 ТР МК карарының 12.18.22, 26 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| зарурлыгын исәпкә алып, әгәр дә туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Гариза тутырганда (2 нче кушымта) мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне күрсәтә: фамилиясен, исемен, атасының исемен, юридик зат атамасын.<br>Этне теркәү турында гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затның дәүләт теркәвенә алынуы турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы– юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда);<br>эттә элегрәк эшләнгән тәңгәлләштерү чараларының булуы турында мәгълүмат (булганда);<br>эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактик ветеринария чаралары турында мәгълүмат (булганда);<br>эт баласына метрика яки эткә шәҗәрә күчермәсе (булганда);<br>этнең фотосурәте (эт хуҗасының теләгенә карап). | № 298 ТР МК карарының 11 п. |
| | Этне теркәү турында таныклык дубликаты бирелү өчен гаризага (6нчы кушымта) түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә | № 298 ТР МК карарының 17 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы– юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда);<br>этне теркәү турында яраксызга чыккан таныклык (булганда). | |
| | Этне теркәү турында таныклыкны алыштыру өчен гаризага (7 нче кушымта) түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы– юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда) | № 298 ТР МК карарының 21 п. |
| | Этне теркәү исәбеннән алу өчен гаризага (8нче кушымта) түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы– юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда) | № 298 ТР МК карарының 25 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Әлеге категориягә карарга мөмкин булган документларны тапшыру таләп ителми | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган килештерү таләп ителгән дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул тартуга нигезләр булып тора:<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тулысынча тапшырмау;<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшыру;<br>дөрес булмаган (ялган) мәгълүматлардан торган документлар һәм гамәлдә булу срогы чыккан документлар тапшыру. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр күздә тотылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр:<br>ике ае тулмаган этне дәүләт теркәвенә | № 298 ТР МК карарының 9, 10 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| | китерү;<br>этне тикшерүгә бирмәү. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.<br>Этне теркәгәндә ветеринария хезмәтләре күрсәтелгән очракта (өстәмә ветеринария хезмәтләре күрсәтү), аларга түләү алына, аның күләме Ветеринария идарәсе тарафыннан билгеләнеп, ГБУ ГГВО һәм РГВО локаль акты нигезендә раслана | № 298 ТР МК карарының 7 п.,<br>№ 298 ТР МК карарының 8 п. |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.<br>Түләү алынмый | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алуга мөрәҗәгать иткәндә чиратта көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләренә чират билгеләнмәгән. | № 601 Указның 1 п. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне, шул исәптән электрон рәвештә дә, теркәүгә алу вакыты | Гариза һәм документлар алынган көнне.<br>Электрон рәвештә гариза ял көнендә алынса – алынган көннән соң килүче эш көнендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектлардан Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматларын | Дәүләт хезмәтен алучыларны кабул итү бу максат өчен махсус бирелгән урыннарда гамәлгә ашырыла, алар түбәндәгечә җиһазландырылган булырга тиеш:<br>этне тикшерү өчен өстәл;<br>тиешле медицина инструментлары;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү һәм саклау өчен кирәкле җиһаз;<br>ветеринария препаратларын саклау өчен җиһаз;<br>мәгълүмати стендлар белән.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз үтеп керүе тәэмин ителә (биналарга уңайлы | № 601 Указның 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр | керү-чыгу һәм алар эчендә йөрү). Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлек итүенең саны һәм вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати коммуникатив технологияләрдән файдаланып | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу вакытын үтәү;<br>3) дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан кылынган Регламентны бозу очраклары (нигезле шикаятьләр) булу-булмау (дәүләт хезмәтен күрсәтүче Ветеринария идарәсе һәм аның карамагындагы ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи затларының гомуми санына прецедентлар, шикаятьләр нисбәте);<br>4) Мөрәҗәгать итүченең, ГБУ ГГВО һәм РГВО белгечләре белән элемтәгә керүенең саны:<br>гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда – икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гариза һәм документларны почта аша җибәргәндә – бердән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән элемтәгә кереп эшләүнең дәвамлылыгы – күп дигәндә 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1) документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспорты тукталышлары зонасында урнашуы;<br>2) белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның зарури санда булуы;<br>3) мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат | № 880 ТР МК карарының 2.4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | ресурсларында, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы.<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналардан инвалидлар файдалана алу мөмкинлеге;<br>5) инвалидларга, биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, башка затлар белән тигез дәрәҗәдә аларга хезмәтләр алуга комачау итүче башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәктә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыннарында күрсәтү каралмаган.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Гаризаны электрон рәвештә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының интернет-кабул итү бүлмәсе (алга таба – Интернет-кабул итү бүлмәсе) аша бирү мөмкинлеге бар.<br>Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеген гамәлгә ашыргач, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон рәвештә күрсәтелә | №63-ФЗ федераль законның 2 ст. 11 п., №210-ФЗ федераль законның 21.1 ст., 21.2 ст. |

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) этне тикшерү;

4) эткә идентификация номеры бирү һәм мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында таныклык бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 3нче кушымтада китерелә.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.

Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Ветеринария идарәсенә, ГБУ ГГВО һәм РГВОга шәхсән, почта аша, телефон аша, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү порталы аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Ветеринария идарәсенең, ГБУ ГГВО һәм РГВО белгече, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән, телефон аша, электрон почта аша һәм (яки) хат аша, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән гаризаның формасы һәм эчтәлеге ягыннан, дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан;

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, почта аша, электрон почта аша, Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша мөрәҗәгать итә, ГБУ ГГВО һәм РГВО дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыра.

Гариза мондый мөмкинлекне гамәлгә ашыргач, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү порталы аша бирелергә мөмкин.

3.3.2. ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты түбәндәгеләрне башкара:

1) гаризаны кабул итә һәм терки;

2) законлы вәкил яисә дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат булып чыгыш ясаучы мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә;

3) әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның булу-булмавын тикшерә;

4) әлеге Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булу-булмауны тикшерә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты, бу Регламентның 2.8 һәм 2.9 пунктларында күздә тотылган документлар кабул итүдән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, түбәндәгеләрне башкара:

1) гаризаны кабул итә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәүгә ала;

2) эткә тикшерү үткәрә;

3) эткә идентификация номеры бирә һәм «Этләрне теркәү журналы»на (әлеге Регламентка 9 нчы кушымта) язып куя;

4) № 298 ТР МК карары белән расланган формада этне рәсмиләштерә, теркәү турында таныклык (алга таба – таныклык) бирә һәм «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) язып куя.

3.3.2.1. Таныклыкта түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) теркәүгә алганда эткә бирелә торган идентификация номеры;

2) эт хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, аны булу урыны яки яшәү урыны буенча теркәү турында, шулай ук фактта яшәү урыны турында мәгълүматлар (эт хуҗасы физик зат булып торса);

3) юридик зат атамасы һәм урнашу урыны (эт хуҗасы юридик зат булып торса);

4) этнең токымы, женесе, төсе, кушаматы, аерым билгеләре, этнең электрон мәгълүмат туплагычка (микрочипка) ия булу-булмавы турында мәгълүматлар;

5) эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактик ветеринария чаралары турында мәгълүмат;

6) этне асрау өчен бүлмә яки җир кишәрлеге адресы.

Мөрәҗәгать итүчегә таныклык бирү турында мәгълүмат «Этләрне теркәү турында бирелгән мәгълүматлар журналы»на (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) кертелә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты, бу Регламентның 2.8 һәм 2.9 пунктларында күздә тотылган документлар кабул итүдән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булган очракта, бер эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) гаризаны теркәүгә яки дәүләт хезмәте күрсәтүгә каршылыклар булуы турында язмача хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтә һәм документларын кире кайтара.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) шәхсән кабул итүдә – әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза алынган көнне һәм ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи затына этне тикшерүгә тәкъдим иткән көнне;

2) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза почта элемтәсе аша яки электрон документлар («Интернет» челтәре аша) рәвешендә алынганда – ГБУ ГГВО һәм РГВОга гариза һәм документлар алынган көнне яки ГБУ ГГВО һәм РГВОга гариза һәм документлар эш вакыты

тәмамланганнан соң алынган очракта – икенче көнне. Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар ял яки эш көннәре булмаган бәйрәм көннәрендә электрон документлар рәвешендә алынган очракта – ГБУ ГГВО һәм РГВОның ял көненнән соң яки эш көне булмаган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны кабул итү, гаризаны мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында теркәүгә алу, этне тикшерү, мөрәҗәгать итүчегә таныклык, гаризаны һәм документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында язма хәбәр рәсмиләштереп тапшыру, мөрәҗәгать итүчегә документларын кире кайтару.

3.4. Дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урынында күрсәтелми.

3.5. Техник хаталарны төзәтү тәртибе.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче, таныклыкта техник хата җибәрелгәнлеген ачыклаган очракта, ГБУ ГГВО һәм РГВОга техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 5нче кушымта), таныклыкта техник хатаның булуы турында дәлилләгән документларны, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә бирелгән таныклыкның төп нөсхәсен тапшыра.

3.5.2. ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфи заты таныклыкта техник хата булу фактын раслаган очракта, мөрәҗәгать итүчегә яңа таныклык бирелә.

Мөрәҗәгать итүчегә таныклык бирү турында мәгълүмат «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) кертелә.

Техник хаталы таныклыкның төп нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылмый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаны кабул итү, теркәү, мөрәҗәгать итүчегә төзәтелгән техник хата турында таныклык бирү.

3.6. Таныклык дубликаты элек бирелгән таныклыкны югалту яки аның яраксызга килүе сәбәпле бирелә.

3.6.1. Таныклык дубликатын бирү әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән, теркәлгән гариза (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) нигезендә, таныклыкны биргән ГБУ ГГВО һәм РГВО тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.6.2. ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты түбәндәгеләрне башкара:

таныклык дубликаты бирү турында гаризаны кабул итә һәм терки;

мөрәҗәгать итүчегә таныклык дубликатын рәсмиләштерeп тапшыра;

таныклык дубликаты бирелүе турында «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на язып куя.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

3.6.3. ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфи заты мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән таныклык дубликатын тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык дубликатын бирү турында гаризаны кабул итү, теркәү, мөрәҗәгать итүчегә таныклык дубликатын бирү.

3.7. Этне теркәү турында таныклык этнең хуҗасы алышыну, аның яшәү яки булу урыны үзгәрү, шулай ук әлеге Регламентның 3.3.2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларның үзгәрүе очрагында алыштырыла.

3.7.1. Таныклыкны алыштыру өчен мөрәҗәгать итүче таныклык биргән ГБУ ГГВО һәм РГВО этне теркәү турында таныклыкны алыштыру турында гариза (әлеге Регламентка 7нче кушымта) белән мөрәҗәгать итә. Гаризага әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кушып бирелә.

Этнең хуҗасы алышынган очракта, әлеге гариза белән этнең яңа хуҗасы мөрәҗәгать итә.

3.7.2. ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты түбәндәгеләрне башкара:

1) таныклыкны алыштыру турындагы гаризаны кабул итә һәм терки; мөрәҗәгать итүченең таныклыгын рәсмиләштерә һәм алыштыра;

2) таныклыкны алыштыру турында «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на язып куя.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфи заты мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән алыштырылган таныклыкны тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклыкны алыштыру турында гаризаны кабул итү, теркәү, мөрәҗәгать итүчегә таныклык рәсмиләштереп тапшыру.

3.8. Эт үлгән очракта яки аны сукбай хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшыру очрагында этне теркәүдән алу.

Мөрәҗәгать итүче этне теркәүдән алу өчен таныклык тапшырган ГБУ ГГВО һәм РГВО этне теркәтү исәбеннән алу турында гариза (Регламентка 8 нче кушымта) белән мөрәҗәгать итә. Гаризага әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кушып бирелә.

3.8.1. ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты түбәндәгеләрне башкара: этне теркәү исәбеннән алу турында гаризаны кабул итә һәм терки; этне теркәү исәбеннән алу турында «Этләрне теркәү журналы»на (әлеге Регламентка 9 нчы кушымта) язып куя. Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

3.8.2. Процедураның нәтиҗәсе: этне теркәү исәбеннән алу турында гаризаны кабул итү, теркәү, этне теркәү исәбеннән алу.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгеләүче Регламент нигезләмәләрен һәм башка норматив хокукый актларны үтәвен, шулай ук җаваплы затларның карар кабул итүен агымдагы контрольдә тотуны Ветеринария идарәсе башлыгы гамәлгә ашыра.

4.2. Агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Планнан тыш тикшерүләр мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча гамәлгә ашырыла.

4.4. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Идарә һәм аның карамагындагы ГБУ ГГВО һәм РГВО эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## V. Ветеринария идарәсенең, ГБУ ГГВО һәм РГВО, Ветеринария идарәсе, ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи затының яки Ветеринария идарәсе дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук кабул иткән карарларына судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи затларының, яисә Идарәнең дәүләт граждан хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен аларның тапшырылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп

алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны яки ялгышларны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү вакыты һәм тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торганда, туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актларында каралмаган булса.

10) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, яисә 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә зарури булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмаулары һәм (яки) ялгыш булуы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.2. Дәүләт хезмәтен алучылар шикаятьне почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы, күпфункцияле үзәк аша җибәрергә, шулай ук ул мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яки мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлар), мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслар) (булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең карары яки гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләгән дәлилләр.

5.4. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгәннән алып 15 эш көне дәвамында.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны яки ялгышларны төзәтүдән баш тартуга шикаять биргән очракта, яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга карата шикаять биргәндә – аны теркәү көненнән алып биш эш көне дәвамында.

5.5. Мөрәҗәгать итүче үзенең дәлилләрен раслаучы документларны (булган очракта), яисә аларның күчермәләрен тәкъдим итә ала.

5.6. Шикаять шәхсән яисә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң, бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында кылына торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен алу максатларында кылырга кирәкле алдагы гамәлләре турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелә алмый дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилле аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 1нче кушымта

## Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре

| Дәүләт учреждениесе атамасы | Почта индексы, адресы | Код | Телефон | Эл. почта адресы |
|---|---|---|---|---|
| «Әгерже районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422231, ТР, Әгерже ш., Ленин ур., 90 | 85551 | 2-46-29 ф | agryz.vet@tatar.ru |
| «Азнакай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423300, ТР, Азнакай ш., Профсоюз ур., 6 | 85592 | 7-22-29 ф | Nailya.Miftahova@tatar.ru |
| «Аксубай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423060, ТР, Аксубай ш.т.б., Мазелин ур., 35 | 84344 | 2-71-58 ф | aksu-vet@mail.ru |
| «Актанышы район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423740, РР, Актаныш ав., Промзона ур., 8 | 85552 | 3-21-19 ф | akt.vet@tatar.ru |
| «Алексеевск районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422900, ТР, Алексеевск ш.т.б., Чистай ур., 5 | 84341 | 2-61-35 ф | Tatyana.Petuhova@tatar.ru |
| «Әлки районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422870, ТР, Базарлы Матак ав., Дорожная ур, 8 | 84346 | 2-02-50 ф | alkeevo.vet@rambler.ru |
| «Әлмәт районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423450, ТР, Әлмәт ш., Совет ур., 3 | 8553 | 32-81-30 | Alm.Gvo@tatar.ru |
| «Апас районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422350, ТР, Апас ш.т.б., Совет ур., 5 | 84376 | 2-15-63 | apasrgvo@rambler.ru |
| «Арча районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422002, ТР, Арча э.б. Комсомол ур., 80 | 84366 | 3-10-93 ф | Arsk.Vettatar@tatar.ru |
| «Әтнә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422750, ТР, Зур Әтнә ав., Совет ур., 1б | 84369 | 2-21-27 | Said.Ahmadullin@tatar.ru |
| «Баулы районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423931, ТР, Баулы, Вахитов ур., 10 | 85569 | 5-77-38 ф | Marina.Usmanova@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Балтач районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422250, ТР, Балтач ав., Комсомол ур., 44 | 84368 | 2-62-57 | Salyahova.Nuriya@tatar.ru |
| «Бөгелмә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423230, ТР, Бөгелмә ш., Залаков ур., 2г | 85594 | 9-11-35 ф | Tatyana.Mosencova@tatar.ru |
| «Буа районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422430, ТР, Буа ш., Р.Люксембург ур., 83 | 84374 | 3-24-04 | Fanciya.Nigmatullina@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422570, ТР, Югары Ослан ав., Чехов ур., 66 | 84379 | 2-16-38 ф | w-uslwet@mail.ru |
| «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422701, ТР, Биектау ав., Үзәк ур., 4 | 84365 | 3-15-09 ф | Alfiya.Zakirova@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422470, ТР, Иске Чүпрәле ав., Сабанту ав., 14 | 84375 | 2-23-77 ф | Guv.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423604, ТР, Алабуга ур., Азин ур., 155 | 85557 | 7-03-37 ф | Elabuga.rgvo@tatar.ru |
| «Зәй районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423522, ТР, Зәй ш., Толстой ур., 85 | 85558 | 6-60-18 ф | Hurshida.Muhamethano@tatar.ru |
| «Яшел Үзән районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422551, ТР, Яшел Үзән ш., Столичная ур., 64 | 84371 | 3-76-21 ф | zel.dol.vet@rambler.ru |
| «Кайбыч районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422330, ТР, Олы Кайбыч ав., Гыйсмәтуллин ур., 5 | 84370 | 2-12-26 ф | Saniya.Gaynullina@tatar.ru |
| «Кама Тамагы районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422820, ТР, Кама Тамагы э.б., Вахитов ур., 4 | 84377 | 2-12-70 ф | Ilgamiya.Mannatova@tatar.ru |
| «Кукмара районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422110, ТР, Кукмара ш., Толстой ур., 1 | 84364 | 2-72-00 ф | kukmor.vet@tatar.ru |
| «Лаеш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422610, ТР, Лаеш ш., Урожай ур., 1 | 84378 | 2-70-01 ф | Aniya.Fatyhova@tatar.ru |
| «Лениногорск районы дәүләт | 423250, ТР, г. Лениногорск, Колхоз | 85595 | 6-17-83 ф | Lvet2008@rambier.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ветеринария берләшмәсе» ДБУ | ур., 14 | | | |
| «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422191, ТР, Мамадыш, Пугачев ур., 25 | 85563 | 3-18-35 ф | Ilyas.Gaptrahimov@tatar.ru |
| «Менделеевск районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423650, ТР, Менделеевск ш., Гунин ур., 1 | 85549 | 2-11-72 ф | mend-vet@mail.ru |
| «Минзәлә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423700, ТР, Минзәлә, Пролетария ур., 60 | 85555 | 3-13-05 ф | menzel.vet@mail.ru |
| «Мөслим районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423970, РР, Мөслим ав., Октябрь., 44 | 85556 | 2-53-88 | Gavis.Gilemov@tatar. ru |
| «Түбән Кама районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423570, ТР, Түбән Кама ш., Төзүчеләр б., а/я 27 | 8555 | 30-51-44 ф | Svetlana.Rahimova@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423190, ТР, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 68 | 84348 | 2-25-21 ф | Gulnur.Rizvanova@tatar.ru |
| «Нурлат районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423040, ТР, Нурлат ш., Линия ур., 38 | 84345 | 2-55-30 | Valerevna.Olga@tatar.ru |
| «Питрәч районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422770, ТР, Питрәч э.б., Төзүчеләр ур., 4 | 84367 | 3-12-56 ф | Elizaveta.Valiullina@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422650, ТР, Балык Бистәсе бис., Шәймәрдәнов ур., 21 | 84361 | 2-29-72 ф | vetrs@mail.ru |
| «Саба районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422060, ТР, Байлар Сабасы ш.т.бис., М.Җәлил ур., 2 | 84362 | 2-30-93 | Taslima.Hanova@tatar.ru |
| «Сарман районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423350, ТР, Сарман э.бис., Профсоюз., 22 | 85559 | 2-40-57 ф | sarm_vet@mail.ru |
| «Спас районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422840, ТР, Болгар ш., Ленин ур., 2а | 84347 | 3-08-41 ф | Dmitriy.Shishkin@tatar.ru |
| «Тәтеш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422370, ТР, Тәтеш ш., Ветгородок, 11А | 84373 | 2-81-13 | Galina:Shemyakova@tatar.ru |
| «Тукай районы | 423806, ТР, Чаллы ш., | 8552 | 46-40-61 ф | Tukay.vet@rambler.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | ЗЯБ бис., Тимер юлчылар тык., 7 | | | |
| «Теләче районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422080, ТР, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 82 | 84360 | 2-10-39 ф | tuliachirgvo1@rambler.ru |
| «Чирмешән районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423100, ТР, Чирмешән районы, Чирмешән ав., Ярминкә тык., 23 | 84396 | 2-51-20 | Gulnur.Sharifullina@tatar.ru |
| «Чистай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422980, ТР, Чистай ш., Г.Тукай ур., 84 | 84342 | 5-17-10 ф | Dinara.Sayfulina@tatar.ru |
| «Ютазы районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423950, ТР, Урыссу бис., Хлебный тык., 1 | 85593 | 2-68-62 ф | rgvo_urussu@mail.ru |
| «Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423806, Чаллы ш., ЗЯБ бис., Автомобильчеләр тык., 8 | 8552 | 46-91-41 ф | gosvet-Chelny@mail.ru |
| «Түбән Кама шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423577, ТР, Түбән Кама ш., Спорт ур., 12в | 8555 | 39-47-79 | Leysan.Gimranova@tatar.ru |
| «Казан шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 420073, ТР, Казан ш., Шуртыгин ур., 4 | 843 | 272-63-92 | gor.vetob@tatar.ru |

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 2нче кушымта

Тәкъдим ителә торган гариза формасы

ГБУ ГГВО яки РГВО башлыгына

кемнән ____________________________
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
____________________________________

телефон: ____________________

# Гариза

Клиник тикшерү үткәрүегезне һәм этне теркәү турында таныклык бирүегезне үтенәм


______________________________________________________________
этнең кушаматы һәм идентификация номеры
______________________________________________________________
туу датасы, җенесе, токымы
______________________________________________________________
хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме яки юридик зат атамасы
______________________________________________________________
физик затның тору яки яшәү урыны буенча теркәү турында мәгълүматлар
______________________________________________________________
(юридик затның урнашкан урыны)
______________________________________________________________
физик затның фактик тору урыны турында мәгълүматлар
______________________________________________________________
эт хуҗасының паспорт мәгълүматлары

Түбәндәгеләр нигезендә эш итүче
______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алучы мәнфәгатьләрен тәкъдим итү вәкаләтләрен раслаучы документның реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 3нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы



ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты

Этккә клиник тикшерү үткәрә → Эткә идентификация номеры бирә, мөрәҗәгать итүчегә таныклыкны рәсмиләштереп бирә, бирелгән таныклыклар журналына язып куя

документларны кире кайтара

Татарстан Республикасында Этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 4 нче кушымта

# Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы

| Этнең идентификация номеры | Эт хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме яки юридик затның атамасы | Эт хуҗасының яки юридик затның фактик адресы | Этләрне теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Этләрне теркәү турында таныклыкны алу турында имза |
|---|---|---|---|---|

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 5нче кушымта

Тәкъдим ителә торган формасы

ГБУ ГГВО яки РГВО башлыгына
кемнән ____________________________
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
____________________________________

телефон: ____________________

# Техник хатаны төзәтү турында гариза

Этне теркәү турында бирелгән таныклыкта
җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне үтенәм.
Төзәтелергә тиешле мәгълүматлар ______________________________________
_____________________________________________________________________
Төзәтелгән рәвештәге мәгълүматлар: _______________________________________
_____________________________________________________________________

Гаризага кушымталар:
1. Җибәрелгән техник хатасы булган таныклыкның төп нөсхәсе;
2. ______________________________________

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында Этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 6 нчы кушымта

Тәкъдим ителә торган формасы

ГБУ ГГВО яки РГВО башлыгына

кемнән ______________________________
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
_____________________________________

телефон: _____________________________

# Таныклык дубликатын бирү турында гариза

Этне теркәү турында таныклыкны югалту (яраксызга килүе) сәбәпле, этне теркәү турында таныклыкның дубликатын бирүегезне үтенәм.
Гаризага кушымталар:
1. ______________________________________________;
2. ______________________________________________.
Түбәндәгеләр нигезендә эш итүче
__________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алучы мәнфәгатьләрен

тәкъдим итү вәкаләтләрен раслаучы документның реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 7 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган формасы

ГБУ ГГВО яки РГВО башлыгына
кемнән ______________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
________________________________________

телефон: __________________________

# Таныклык алыштыру турында гариза

Этнең хуҗасы алышыну/ эт хуҗасының яшәү яки булу урыны үзгәрү/ этне теркәү турында таныклыкта күрсәтелгән мәгълүматларның үзгәрүе сәбәпле, этне теркәү турында бирелгән таныклыкны алыштыруыгызны үтенәм.

Гаризага кушымталар:

1. ____________________________________________________________;
2. ____________________________________________________________.

Түбәндәгеләр нигезендә эш итүче

_______________________________________

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алучы мәнфәгатьләрен тәкъдим итү вәкаләтләрен раслаучы документның реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 8нче кушымта

Тәкъдим ителә торган формасы

ГБУ ГГВО яки РГВО башлыгына
кемнән ______________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
______________________________

телефон: ________________________

# Этне теркәүдән төшерү турында гариза

Эт үлү/этне сукбай хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшыру сәбәпле, минем карамактагы этне теркәү исәбеннән алуыгызны үтенәм
Гаризага кушымталар:
1. ______________________________________;
2. ______________________________________.
Түбәндәгеләр нигезендә эш итүче
____________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алучы мәнфәгатьләрен тәкъдим итү вәкаләтләрен раслаучы документның реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 9 нчы кушымта

## Этләрне теркәү журналы

| Хайванның тасвирламасы | | | | | | | | | Котыру авыруына каршы вакцинация һәм башка эшкәртүләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| №п/п | Эт хуҗасының ФИО | Этне асрау адресы | Этнең идентификация номеры | кушаматы | Туу датасы | җенесе | токымы | төсе | Вакцинация, эшкәртү датасы | Вакцина, серия | Ветеринар табиб имзасы | Башка билгеләр |

Татарстан Республикасында
Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына (белешмә) кушымта

Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе

| Вазыйфа, ФИО | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Идарә башлыгы | (843) 221-77-47 | guv@tatar.ru |
| Идарә башлыгы урынбасары | (843) 221-77-49 | Ayrat.Garaev@tatar.ru |
| Дәвалау-профилактика чаралары бүлеге башлыгы | (843) 221-75-88 | Sultan.Latypov@tatar.ru |
| Хокук бүлеге башлыгы | (843) 221-75-90 | Azatovich.Artur@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы | Сайт |
|---|---|---|---|---|
| 420014, Казан ш., Ирек мәйданы, 1 йорт | Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы | (843) 264-76-80 | Marat.Harisov@tatar.ru | www.prav.tatarstan.ru |